Республика Татарстан
Совет Карашай-Сакловского
сельского поселения
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл
җирлеге советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 апрель 2025 ел № 106

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Советның 26.11.2021 ел, № 28 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 28.12.2024 елгы 540-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 49 пункты, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге Уставы нигезендә Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Советның 26.11.2021 ел, № 28 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.18 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контроль (күзәтчелек) чарасы актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең акыллы срокларын, шулай ук Контроль төре турындагы Федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарсан Ресаубликасы
Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы В.В.Хөсниева